
# ТАТАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ ХАТЫН-КЫЗ ПРОФЕССОРЫ ЗӘЙНӘП ЯКУПОВА

**Рәшит Әгъләм улы Шакирҗанов,**
Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты,
Россия, 420043, Казан, Зеленая ур., 1 нче йорт,
rashitagl@mail.ru



**YAKUPOVA ZAINAP NAZIPOVNA** (1913-1985) − obstetrician-gynecologist, MD (1963), Professor (1965), Honored Doctor of the TASSR(1964), Honored Scientist of the TASSR(1982).

In 1950-1985 Yakupova Z.N. worked at the Kazan Medical Institute. Since 1968, she was the Head of the Department of Obstetrics and Gynecology No2.

She is the author of the works on obstetric bleeding and intrauterine contraception.

**ЯКУПОВА ЗӘЙНӘП НӘҖИП кызы** (1913-1985) – акушер-гинеколог, медицина фәннәре докторы (1963), профессор (1965), ТАССРның атказанган табибәсе (1964), ТАССРның атказанган фән эшлеклесе (1982). 1950-1985 елларда Казан медицина институтында, 1968 елдан Икенче акушерлык һәм гинекология кафедрасы мөдире.

Хезмәтләре акушерлыкта кан китүгә, балага узудан саклануга карый.

**ЯКУБОВА ЗАЙНАБ НАЗИПОВНА** (1913-1985) − акушер-гинеколог, доктор медицинских наук (1963), профессор (1965), заслуженный врач ТАССР (1964), заслуженный деятель науки ТАССР (1982). В 1950-1985 гг. в Казанском медицинском институте. С 1968 г. заведующая кафедрой акушерства и гинекологии №2.

Труды по вопросам акушерских кровотечений, внутриматочной контрацепции.

Зәйнәп Якупова 1913 елның 18 мартында Оренбург өлкәсенең Бозаулык шәһәрендә дөньяга килә. Әтисе Нәҗип – тәҗрибәле эшче, әнисе Гайшә – хуҗабикә була.

Унъеллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Зәйнәп 1931 елда Казан ветеринария институтына укырга керә. Студент елларында тере организмнар биохимиясе юнәлешендә фәнни тикшеренүләр алып бара. 1935 елда институтны ветеринария табибы белгечлеге буенча кызыл дипломга тәмамлап, тикшеренүләрен биохимия кафедрасы каршындагы аспирантурада дәвам итә. Әмма тикшеренү нәтиҗәләре аны канәгатьләндерми, өченче уку елында ул аспирантураны ташлап, 1937–1941 елларда Казан медицина институтында укый. Ветеринария институтында үзләштергән белемнәре аңа икенче югары белем алырга ярдәм итә. Аны П.В.Маненков кафедрасында табиб-ординатор итеп калдыралар. Әмма Бөек Ватан сугышы Зәйнәп Якуповага планнарын тормышка ашырырга комачаулый. Сугыш елларында ул Казан гарнизонының хәрби-табиби комиссия

рәисе, Казан медицина институтының санитар-гигиена факультеты деканы урынбасары, ТАССР Сәламәтлек министрлыгының махсус поликлиникасында табиб-консультант булып тора.

1947 елда Зәйнәп Якупова акушерлык һәм гинекология кафедрасы ассистенты итеп билгеләнә, П.В.Маненков җитәкчелегендә фәнни эзләнүләрен дәвам итеп, 1951 елда «Викасол һәм бала табучыларда, яңа туган балаларда кан китү» дигән темага кандидатлык диссертациясен яклый.

1951 елда Казан медицина институтында икенче акушерлык һәм гинекология кафедрасы оештырыла. З.Н.Якупова да шунда күчерелә һәм 1985 елның июненә кадәр хезмәт итә. 1954 елдан кафедра доценты вазифаларын башкара, ә 1957 елда Икенче акушерлык һәм гинекология кафедрасы доценты итеп раслана. 1962 елда Зәйнәп Нәҗип кызы «Бала тудыруның икенче һәм өченче чорларында «Р», «М» питуитриннарын һәм окситоцинны кан тамырына глюкоза белән кертү» дигән темага докторлык диссертациясен яклый.

1969 елда З.Н.Якупова Казан медицина институтының Икенче акушерлык һәм гинекология кафедрасы мөдире итеп билгеләнә, аны 1984 елга кадәр җитәкли. Аның җитәкчелегендә кафедра төгәл гамәли юнәлеш ала. Кафедраның клиник базалары киңәйтелә: ул шәһәрдәге алты бала тудыру йортында һәм хатын-кызлар консультацияләрендә дәвалау эшләрен җитәкләп бара. Шул чорда Зәйнәп Якупова кафедраның өч фәнни юнәлешенә нигез сала. Алар – аналыкның кыскару эшчәнлеген көйләү, аналык эче контрацепциясе һәм сәнәгатьтә хатын-кызларның һөнәри авыруларына профилактика үткәрү. Йөккә узуга каршы ул уйлап тапкан чаралар бала төшерү санын кискен киметүгә китерә. Аның инициативасы белән Казанда оештырылган «Йөккә узуга каршы профилактика» үзәге аналыкны саклау чараларының нәтиҗәле һәм куркынычсыз булуын күрсәтә.

Соңрак, шәкертләре Р.Х.Әмиров, Р.С.Барышкина, Б.М.Кошкин белән берлектә, З.Н.Якупова күп кенә гамәли мәсьәләләр чишә, экспозиция вакытын һәм дәвамлыгын билгеләү, кайбер иммунология, бала төшерү, эре сәнәгать предприятиеләрендә эшләүче хатын-кызларның авырып китү мәсьәләләрен өйрәнә. Бу эзләнүләр аларның сәламәтлеген яхшыртуга булыша, ә ТАССРның планнан тыш йөккә узуга каршы профилактика үзәге РСФСРда төп контрацепция үзәге итеп билгеләнә.

Токсоплазма буенча лаборатория, «Көтелмәгән йөклелек профилактикасы» буенча Республика үзәге һәм аның филиаллары оештырыла. Шул сәбәпле аналык эчендә кулланыла торган контрацепцияләрне илебездә җитештерү һәм аларны кулланышка кертү юнәлешендә Казан алдынгы урынга чыга, ә Татарстан гаиләне планлаштыру хезмәте буенча алдынгы тәҗрибә базасы итеп танылa.

Профессор Зәйнәп Якупованың фәнни өлкәдә төп игътибары гамәли мәсьәләләргә – акушерлыкта кан китү, бала табу аномалияләрен профилактикалау һәм дәвалау, хатын-кызларда һөнәри авырулар башлану сәбәпләрен ачыклау һ.б. юнәлтелә. Ул җитәкләгән коллективның бу юнәлештә ирешкән уңышлары фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан хуплана һәм уңай бәя ала, бүгенге көндә дә кайбер фәнни эшләнмәләр Зәйнәп Якупова исемен йөртә. Мәсәлән, «Атоник кан агуны Якупова буенча профилактикалау», «Якупова буенча гормональ кыстыргычлар», «32 атналык йөклелектә аналыктагы баланың авырлыгын Якупова буенча билгеләү» һ.б.

З.Н.Якупова Совет хатын-кызлары комитеты җитәкчесе, беренче хатын-кыз космонавт Валентина Терешкова белән тыгыз хезмәттәшлек итә, комитет карары буенча Германия (1972), Израиль (1973), Кипр (1973), Югославия (1975), Вьетнам (1976) һ.б. илләрдә чыгышлар ясый, төрле чараларда катнаша. 1975 елда гына да «Белем» җәмгыяте кысаларында алтмышлап лекция укый. Моннан тыш, 1978–1984 елларда РСФСР Югары суды утырышларында, «Советская женщина», «Азат хатын» журналларының редколлегиясе эшендә дә актив катнаша.

З.Н.Якупова җитәкчелегендә 7 кандидатлык һәм 2 докторлык диссертациясе яклана.

1974 елда профессор Зәйнәп Якупова редакциясендә «Акушерско-гинекологическая профпатология» дигән җыентык дөнья күрә. Ул күп кенә журналларда мәкаләләр бастыра, 8 методик тәкъдим, 4 патент һәм 6 рационализаторлык, 77 басма хезмәт авторы.

З.Н.Якупова Совет хатын-кызлары комитеты, берничә тапкыр РСФСР Югары Суды әгъзасы, район һәм шәһәр Советлары депутаты, «Азат хатын» журналы редколлегиясе, ТАССР һәм РСФСР акушер-гинекологлары җәмгыятьләренең идарә әгъзасы, биш ел дәвамында Казан шәһәренең

баш акушер-гинекологы булып тора. Ул – СССРда «акушерлык һәм гинекология» буенча профессор дәрәҗәсенә лаек булган беренче татар хатын-кызы. З.Н.Якупова эшчәнлеге «ТАССРның атказанган табибы», «ТАССРның атказанган фән эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәр, Хезмәт Кызыл байрагы һәм II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бәяләнә.

Иң гуманлы һөнәр иясе, кешелек дәвамын − кечкенә баланы каршы алган, аның сәламәт үсүенә юл салган табибә һәм галим Зәйнәп Нәҗип кызы Якупова 1985 елның 6 октябрендә Казанда вафат була.

**Әдәбият**


1. Татарский энциклопедический словарь. Казань, 1999. С. 683
2. Мәшһүр татар галимнәре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 308-316 б.